**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XL УТЫРЫШЫ**

**КАРАР № 62**

**Баек авыла** **2023 ел 16 декабрь**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» 2023 елның 17 маендагы 51 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә турында» 2023 елның “17” маендагы 51 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.12 нче пункт 3 нче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.12. Муниципаль хезмәткәргә классныы чин бирү турындагы карар, 3 өлешнең 3.7 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, сыйныф чинын барлык кирәкле документлар белән җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына бирү турында тапшыру кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш»;

1.2. 3.6.1 пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.1. Сыйныф чинын бирү көне дип сыйныф чинын бирү турында карар кабул итү көне санала».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баек авыл җирлеге башлыгы: М.Ф.Фахерлегаянов